*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№5 (66) Февраль, 2025 нче ел

**Бу санда**

*Олимпиадалар дәвам итә* 2

*Гимназиядә хәрби-патриотик айлыгы* 3

*Укучылар иҗаты* 4

*Ял сәгатьләрендә* 4




**2025 ел — Ватанны саклаучылар елы**

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ




### *Хөрмәтле гимназия ир-егетләре, укучы егетләр!*

*Ватанны саклаучылар көне – батырлык, намус һәм кыюлык көне белән ихластан ир-егетләребезне котлыйбыз.*

*Бүгенге бәйрәм көчле рухлылык, ир-егетләрнең кыюлык, намус һәм абруй шикелле сыйфатларга ия булуларын тагын бер кат раслый торган тантана.*

*Сезгә һәм якыннарыгызга тыныч күк йөзе, ныклы сәламәтлек, бәхет-шатлык, рухи һәм матди байлык, һәр эшегездә бары тик уңышлар гына телибез.*

***"Тылсым+" газетасы редколлегиясе***

### Ел укучысы




2025 елның 30 гыйнварында, Мөслим лицее базасында 4 нче сыйныф укучылары арасында, сәләтле балаларны ачыклау максатында «Ел укучысы» муниципаль конкурсының финал туры узды. Конкурсның зона этабында 30 катнашучы арасыннан финалга 7 укучы чыкты, алар үз проектларын лаеклы якладылар.

Финалга чыгучылар арасында гимназиянең 4 нче б сыйныфы укучысы Шәйхетдинов Данис та бар. Ул «Яшь эрудит» номинациясендә җиңү яулады.

Данисны конкурска укытучысы Латыйпова Ирина Владимировна әзерләде.

### Спартакиада ярышлары тәмамланды

Оешма-предприятиеләр арасында узган XXXV спартакиада ярышларында Мәктәпләрнең җыелма командасы беренче урынга лаек булды. Җиңүчеләр 100 мең сумлык сертификат, кубок, статуэткалар һәм медальләр белән бүләкләнделәр.






*Гимназия яңалыклары - безнең рәсми сайтта https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym*

*Гимназия яңалыклары - социаль челтәрдә https://vk.com/gymnasiummus*

# ОЛИМПИАДАЛАР ДӘВАМ ИТӘ

***Фән олимпиадалары җиңүчеләрен котлыйбыз!***

**Россиякүләм һәм Республикакүләм фән олимпиадалары февраль аенда да дәвам итте. Бүген безнең 16 призлы урыныбыз бар.**

Нәтиҗәләр түбәндәгечә: математика фәне призеры 11 нче а сыйныфы укучысы **Шәрифуллин Рәфил** (укытучысы Асылгәрәева Г.Ә.), 9 нчы а сыйныфы укучылары **Латипова Алинә, Зиннурова Илзирә**, 10 нчы сыйныфтан **Газетдинова Азалия, Газетдинова Адилә** - биология фәненнән Республикакүләм олимпиаданың йомгаклау этабы призерлары (укытучылары – Бариева Л.Ф.), хокук фәненнән 11 нче а сыйныфы укучысы **Шәрипов Булат** (укытучысы – Мирзаянов А.Ф.), 8 нче б сыйныфы укучысы **Ильясова Аделина** (укытучысы – Мөхәммәтдинова Р.Р.), географиядән 11 нче а сыйныфы укучылары **Әхмәтҗанов Фирзәр, Шәрипов Булат** (укытучылары - Юлдашев И.Н.), физик тәрбиядән 11 нче а сыйныфы укучысы **Сәйфуллин Рушан** (укытучысы – Булатов Д.Д.), 10 нчы сыйныф укучылары **Нәбиев Камил**, **Хатипова Ралина** (укытучылары - Шәйхетдинов Д.Г.) призлы урын яуладылар.

***Олимпиада призерларын һәм аларга белем бирүче мөгаллимнәребезне чын күңелдән тәбрик итәбез. Олимпиадаларда катнашучыларга киләчәктә уңышлар телибез!***



**Латипова Алинә, Зиннурова Илзирә, Газетдинова Азалия һәм Адилә**



**Ильясова Аделина**



**Әхмәтҗанов Фирзәр**



**Шәрифуллин Рәфил**



**Шәрипов Булат**



**Сәйфуллин Рушат**



**Хатипова Ралина**



**Нәбиев Камил**

# ГИМНАЗИЯДӘ ХӘРБИ-ПАТРИОТИК АЙЛЫГЫ

**Хәрби-патриотик айлык кысаларында гимназиядә бик күп чаралар үтте:**

Һәр елның 15 феврале Ватаныбыздан читтә хәрби бурычларын үтәгән интернационалист сугышчыларны искә алу көне буларак билгеләп үтелә. Бу көн 1989 елда Әфганстаннан Совет сугышчыларын чыгаруга багышланган. Гимназиябездә Әфган сугышы ветераннары Солтанов А.М, Мирзаянов А.Ф. белән бик эчтәлекле очрашу узды. Килгән ветераннарыбызга, очрашуны оештырган Үзәк китапханә хезмәткәрләренә бик зур рәхмәтебезне җиткерәбез.




Педагог–китапханәче Солтанова Г.М. 8 нче а, 8 нче в сыйныф укучылары белән татар шагыйре, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең тууына 119 ел тулу уңаеннан китапханә дәресе үткәрде. Балалар шагыйрьнең фронттагы авыр көннәре, концлагерьларда, фашист төрмәләрендә үткән коточкыч вакытлары турында белделәр. Әсирлектә Муса Җәлилнең бердәнбер коралы аның үз халкына багышлап язган шигырьләре булган.



Хәрби-патриотик айлык кысаларында 8 нче а, 8 нче в сыйныфлары укучылары өчен "Бөек Ватан сугышы" дигән темага викторина үткәрелде.

********

6 нчы а сыйныфы укучылары "Солдатны котла!" акциясенә кушылдылар. Алар СВО дагы солдат абыйларга хатлар яздылар. “Ватанны саклаучылар көне" белән дә котладылар.

********

“Ватанны саклаучылар көне”нә багышлап, башлангыч сыйныф укучылары рәсемнәр ясадылар, урта сыйныф укучылары стенгазеталар чыгарды.

4 нче сыйныф укучылары Мөслимнең картлар йортына барып анда тәрбияләнүчеләр белән очраштылар. “Ватанны саклаучылар” елы уңаеннан "Кирәкми безгә сугыш, безгә тынычлык кирәк" дигән театральләштерелгән музыкаль чара әзерләп, өлкәннәргә тәкъдим иттеләр. Г.Насыйриның "Ана күңеле" әсәренә нигезләнеп төзелгән театраль күренешне әбибабайлар бик яратып карадылар.



Ватанны саклаучылар көне алдыннан, 20 февраль көнне 3 нче а һәм 3 нче б сыйныфлары катнашында "Күңелле стартлар" спорт чарасы узды.



Гимназиядә «Ягез әле, егетләр!» бәйгесе үтте. 9-11 сыйныфта укучы егетләр, өч командага бүленеп, көч, белем, җитезлек, иҗадилыкта, зирәклек-тапкырлыкта көч сынаштылар.

11 нче сыйныф егетләре беренче урынга, 10 нар икенче, 9 лар өченче урынга лаек дип табылдылар.



# БАЛЫК ҖЕНЕ КАГЫЛГАН



Нурсолтанның әтисен авыл халкы «балык җене кагылган Ильяс", дип йөртә. Күпме генә тырышса да, Нурсолтан бу сүзләрнең мәгънәсенә һич төшенә алмый. Ярар балыгын аңлый, анысы суда яши. Ә менә җен дигәннәрен күргәне юк бит аның. Әбисе дә: "Җен" сүзен җенем сөйми, син дә әйтмә, үз исемнәрен ишетүгә янына килерләр дә, начарлыкка котыртырлар - имансызлар," – ди. Аңламассың инде, әтиемә кагылганнар, ә минем янга нишләп килергә ярамый аларга, ә?

Нурсолтанның әтисе бит бик яхшы кеше. Аны өйдә дә, эшендә дә гел мактап кына торалар. Урамга чыккач та: "Әтиең кебек акыллы, батыр бул!" – диләр Нурсолтанга. Ул кечкенә булса да, шулар турында уйлый-уйлый аптырап бетә. Нурсолтанның әтисе әз генә вакыты булса, балыкка барырга ярата. Иртә диме, кич диме, салкын диме, кыш диме, кармагын ала да балыкка китә. Бер тапкыр үзе белән Нурсолтанны да алып барды ул балыкка. Ләкин балык тотуы гына охшамады аңа. Ул черки тешләве, тын да алмыйча тик кенә утыруы бер дә кызык булмады.

Бүген дә иртән иртүк чыгып киткән әтисе, төш вакытында лачма су булып кайтып керде.

- Абау, Ходаем, нәрсә булды? Әллә су төбенә төшеп киттеңме? Гомерләрең булган икән, и балам-балам... Шул балык дип үләсең инде, балык җене кагылган нәрсә," – дип, әбисе такмаклый-такмаклый сөйләнде. Чиста коры киемнәр кигәч, әтисе Нурсолтанны үз янына чакырып алды да, каты итеп кочаклап, тез башына утыртты.

- Улым, син безнең бердәнбер акыллы улыбыз. Син әтиең, әниең, әбиең әйткәннәрне тыңларга тиеш, беләсеңме? – диде.

- Белә-әәәм,- дип сузды Нурсолтан.

- Белсәң, менә шул, бүген 2 шук малай су буена килгәннәр дә, шуабыз дип, бозга кергәннәр. Ә хәзер боз юка. Алар уйнаган урында ярылып киткән дә, малайлар суга чумган. Ярый әле, мин яр буенда гына балык тота идем. Нинди тавыш микән дип барсам, чәбәләнеп яталар.

- Язгы боз, ястык калынлыгы булса да, ышанма, - дип сүзгә кушылды әбисе.

- Көч-хәл белән сөйрәп чыгардым тегеләрне. Өшеп, туңып беткәннәр, хәтта кечкенәсенең еларга да хәле калмаган иде. Менә шул улым, боз өстендә бөтенләй уйнарга ярамый, аңладыңмы?

- Аңладым! - диде Нурсолтан.

Шулчак ишек ачылды һәм бусагадан күрше Раилнең әтисе белән Нәфиснең әнисе килеп керде.

- Исәнмесез, Ильяс абый. Синең алда без бурычлы, сиңа бик зур рәхмәт инде. Балаларыбызның гомерен саклап калгансыз бит. Мәгез әле, әзме-күпме көчтәнәч, - дип берсе 3 литрлы банка белән бал, ә икенчесе акча сузды.

- Мин аларны кемдер, ни беләндер - түләсен дип коткармадым. Балаларыгыз исән калган икән, гомерләре булган, димәк. Ә бу көчтәнәчләрегезне әнә Әнисәнең ятим балаларына кертегез. Балаларыгызга бозда уйнарга ярамаганлыгын яхшылап аңлатырга кирәклеген онытмагыз, - диде Нурсолтанның әтисе.

- Шулкадәр яхшы кеше булсаң да, булырсың икән, Ильяс абый, - диде Нәфиснең әнисе.

- Күзләр генә тимәсен, Ходай озын, сәламәт гомер бирсен сезгә. Ә Хәдичә әби сезгә шушындый акыллы бала үстергән өчен Ходай бәхетле картлык бирсен, - дип, кул биреп саубуллашты Раилнең әтисе.

Бу хакта бер генә түгел, мең мәртәбә сөйләде авыл халкы. Нурсолтанның әтисе генә берәүгә дә мактанмады.

***Хәсәнова Асылъяр,***
***5 нче б сыйныфы укучысы***

<u>***Укучылар иҗаты***</u>

# ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ

<u>***Уйлап кара***</u>



1. «25»тән «3»не ничә тапкыр алып була?
2. Елда, гасырда таба алмаган нәрсәне сез секундларда, минутларда, көннәрдә таба аласыз?
3. Ике ат бергә 20 километр чапкан. Ә һәр ат аерым-аерым ничә километр чапкан?
4. Мин һәркөнне чәч кисәм, әмма минем чәч озынлыгы үзгәрми. Нигә?
5. Нәрсә күбрәк булган саен, син азрак күрәсең?
6. Нәрсәне уң кулыгыз белән җиңел тота аласыз, әмма беркайчан да сул кул белән тота алмаячаксыз?
7. Машинада ике әти һәм ике ул бара, ә барлыгы машинада өчәү. Ничек алай?
8. Биш бүлмә, бер ишек. Нәрсә турында сүз бара?
9. Сары яулыкны Кара диңгездә юсаң, яулык нинди төстә булачак?
10. Ул утырып кына йөри.

***P.S. Кызык сорауларга - көтелмәгән җавапларны электрон адрес буенча кабул итәбез.***

ТЫЛСЫМ+
**Февраль, 2025 нче ел**
**№5 (66)**
***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Замалова Зәринә
**Корректорлар:** Хәйруллина Диләрә
**Корреспондентлар:** Насырова Мәрьям, Фәхрәзиева Алинә
**Дизайнер:** Мостафина Рәйлә
**Компьютерда җыючылар:** Вагыйзов Айзат, Сәләмов Наил

***2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә***
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim2014@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3)
**Тираж:** 100